**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Илбәк авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Илбәк авылы № 137 21 гыйнвар 2025 ел

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Илбәк авыл җирлеге» Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Җирле үзидарә турындагы федераль һәм республика законнарындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә

Илбәк авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 2012 елның 16 гыйнварындагы 30 номерлы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Илбәк авыл җирлеге» Уставына (24.09.2012 №44, 05.08.2013 №63, 22.10.2014 №100, 30.09.2015 №9, 15.11.2016 №39, 17.04.2018 №86, 03.09.2018 №99, 05.11.2019 №140, 17.11.2020 №13, 25.02.2022 №47, 16.02.2024 №106 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 статья. Авыл җирлеге һәм аның статусы

1. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 27 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә авыл җирлеге статусы бирелгән.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми исеме, кыскартылган исеме «Илбәк авыл җирлеге» (алга таба текст буенча - җирлек).

3. «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы составына керә.».

1.2. 6 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 20 пунктны өстәргә:

«20) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон, хуҗалык кенәгәләрендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

б) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

1.3. 19.1 статьясындагы 5 пунктының икенче абзацында «1-7 пунктларында» сүзләрен “1-7 и $9^2$» сүзләренә алмаштырырга.

1.4. 29 статьяда:

а) 6 өлешнең 2 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларында «, сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 7 өлештә «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәис) сүзләренә алмаштырырга;

в) 8 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәис) сүзләренә алмаштырырга.

1.5 39  статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 10.1 пункт өстәргә:

«10.1) аларга чит ил агенты статусы алу;»;

б) 2 өлештә «1-7, 10 һәм 11 пунктларында» сүзләрен «1-7, 10, 10.1 һәм 11 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга.

1.6. 44 статьяның 1 өлешендәге 12 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

1.7. 47 статьяда:

а) 1 өлешнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзацны өстәргә:

«-Шәхси ярдәмче хуҗалык турында»гы 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә ала.»;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирлекнең Башкарма комитеты муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып тора.

Җирлекнең муниципаль контроль өлкәсендәге Башкарма комитеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу;

2) җирлек территориясендә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру;

3) «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар нигезендә башка вәкаләтләр.

Муниципаль контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыру функцияләре әлеге органнарның статусын билгеләүче хокукый актлар нигезендә җирлек башкарма комитеты органнарына йөкләнергә мөмкин.

Муниципаль контроль төрләрен оештыру һәм гамәлгә ашыру «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән җайга салына.».

1.8. 68 статья түбәндәге эчтәлекле 3 өлешне өстәргә:

«3. Җирле үзидарә органнары муниципаль милектәге электр челтәре оешмасы яисә Татарстан Республикасы чикләрендә эшләүче территориаль

челтәр оешмасы системасындагы электр челтәре хуҗалыгы объектларын, Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда түләүсез биләүгә һәм алардан файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыра.».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Дәүләт теркәвеннән соң, әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча http://aznakayevo.tatarstan.ru, Илбәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Р.К.Галимҗанова